ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

______________　　с. Верхний Услон　　______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябреннән 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) берсе мобилизацияләнгән баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 2 пункты, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнарының хәрби хезмәткә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гаиләләренә ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәм итү максатыннан, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябреннән 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) берсе мобилизацияләнгән баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итергә.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарда каралган ярдәм чараларын күрсәтү 2022 елның 1 ноябреннән алып һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби мобилизация хезмәте узу вакытында гамәлгә ашырыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе　　　　　　　　　　И.И. Шакиров

Әзерләде һәм бастырды
Р.Х. Яковлева
5 нөсхәдә